КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1114

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан, террорчылыктан саклау мәнфәгатьләрендә категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлеген формалаштыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне һәм сәүдә объектлары (территорияләре) куркынычсызлыгы паспорты формасын раслау турында» 2017 ел, 19 октябрь, 1273 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан, террорчылыктан саклау мәнфәгатьләрендә категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлеген формалаштыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль,

324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нчы; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 361 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 972 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 нче бүлекнең 4.1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1.110 нчы пунктча өстәргә:

«4.1.110. Территориаль иминлек органы, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең территориаль органы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының территориаль органы белән килештереп, Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан, террорчылыктан саклау мәнфәгатьләрендә категорияләргә бүленергә тиешле сәүдә объектлары (территорияләре) исемлеген формалаштыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин